**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (84348) 2-31-00, факс: (8-4348) 2-20-22

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-4348) 2-31-00, факс: (84348) 2-20-22

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2026 елның 18 июненнән — № 10-64

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль-шәхси партнерлык турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 26 маендагы 34-270 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә дәүләт-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы, «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында дәүләт-хосусый партнерлык турында» 2011 елның 1 августындагы 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2023 елның 26 маендагы 34-270 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль-шәхси партнерлык турындагы Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2024 елның 27 декабрендәге 51-393 номерлы; 2025 елның 4 сентябрендәге 60-458 номерлы карары белән үзгәртелгән редакциядә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 7 бүлекнең 7.2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 7.2.2 пунктчасы белән тулыландырырга:

«7.2.2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан килешүләрне гамәлгә ашыруны мониторинглауны башкару максатларында Россия Федерациясе территориясендә төзергә планлаштырыла торган, гамәлгә ашырыла һәм гамәлгә ашырылган килешүләр турында «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында каралган тәртиптә белешмәләрне «Идарә» дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертүнең тулылыгын, дөреслеген һәм үз вакытында булуы тәэмин ителә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

4. Әлеге карар 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы Е.А.Тарнавский